# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Урта Тигәнәле авыл җирлеге Түбән Тигәнәле авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 14 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 12.10.2022,14.10.2022 да узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Түбән Тигәнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1. Авыл эчендәге юлларны төзү һәм ремонтлау
2. Күмү урыннарын төзекләндерү
3. Кыш һәм җәй көннәрендә юлларны чистарту
4. Су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау һәм салу
5. Су этем манарасын алмаштыру;
6. Янгын гидрантын көйләү

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 134 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 118 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 109 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 9 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендәге Түбән Тигәнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Түбән Тигәнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым

кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1. Авыл эчендәге юлларны төзү һәм ремонтлау
2. Күмү урыннарын төзекләндерү
3. Кыш һәм җәй көннәрендә юлларны чистарту
4. Су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау һәм салу
5. Су этем манарасын алмаштыру;
6. Янгын гидрантын көйләү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Урта Тигәнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы И.К.Хаматвәлиев